МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2018 Казан ш. № 21-41-148

Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә тапшырылган субсидияләр калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗның булуын дәлилләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясындагы 4.1 пункты нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә тапшырылган субсидияләр калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗның булуын дәлилләү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
14.07.2018 № 21-41-148
боерыгы белән расланды

Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә тапшырылган субсидияләр калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗның булуын дәлилләү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләренең гамәлгә куючылары (алга таба – гамәлгә куючылар) функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә тапшырылган субсидияләр (алга таба – максатчан субсидияләр) калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗның булуын дәлилләү процедурасын билгели.

2. Учреждение файдаланылмый калган максатчан субсидияләр калдыкларына ихтыяҗның булуын дәлилләү өчен, агымдагы финанс елының беренче өч эш көне эчендә гамәлгә куючысына җибәрә:

а) максатчан субсидиянең файдаланылмый калган калдыгына ихтыяҗның булуын дәлилләгән нигезләр белән язмача мөрәҗәгать;

б) максатчан субсидия бирү турында килешүдә күздә тотылган максатчан субсидиядән файдалану турында хисап;

в) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 25 март, 2011 ел, № 33н боерыгы белән расланган Дәүләт (муниципаль) бюджет һәм автоном учреждениеләрнең еллык, кварталлык бухгалтерия хисабын төзү, тапшыру тәртибе турында инструкция, Учреждениенең йөкләмәләре турында хисап (ОКУД буенча форма коды – 0503738) һәм Учреждениенең дебиторлык һәм кредиторлык бурычы буенча мәгълүматлар (ОКУД буенча форма коды – 0503769);

3. Гамәлгә куючы агымдагы финанс елының 20 гыйнварына кадәрге срокта учреждение тапшырган бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерүне һәм, җыелма мәгълүмат рәвешендә, максатчан субсидияләр калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗның булуын раслау турында карар кабул итүне тәэмин итә.

4. Файдаланылмый калган максатчан субсидияләр калдыкларына ихтыяҗның булуын раслау турында җыелма мәгълүматлар түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

учреждение атамасы;

максатчан субсидия атамасы;

бюджет чыгымнарының бюджет классификациясе кодлары буенча максатчан субсидияне тоту юнәлешләре;

агымдагы финанс елының 1 гыйнварына максатчан субсидиянең файдаланылмый калган калдыгы суммасы;

үткән финанс елында төзелгән килешү буенча максатчан субсидия суммасы;

агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кабул ителгән һәм үтәлмәгән йөкләмәләр суммасы;

ихтыяҗы расланган файдаланылмый калган максатчан субсидия калдыгы суммасы;

максатчан субсидия калдыкларыннан шул ук максатта файдалануга ихтыяҗның нигезләнеше;

агымдагы финанс елына бюджетта максатчан субсидия калдыкларына ярашлы чыгымнарның булуы (булмавы).

5. Гамәлгә куючы кабул ителгән карарны, карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә, учреждениегә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җиткерә.

6. Учреждение гамәлгә куючыдан карар алынганнан соң өч көн (эш көннәрендә исәпләнелә) эчендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 02.03.2016 ел, № 21-53-10 боерыгы (алга таба – 02.03.2016 ел, № 21-53-10 ТР Финанс министрлыгы боерыгы) белән расланган Үзләренә лицевой счетлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан тапшырылган файдаланылмый калган субсидияләр калдыкларын түләтү тәртибенә №1 кушымта нигезендәге форма буенча максатчан субсидияләр белән операцияләр турында мәгълүматларны гамәлгә куючыга раслауга тапшыра.

7. Гамәлгә куючы раслаган, бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар ТР Финанс министрлыгының 02.03.2016 ел, № 21-53-10 боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла.

8. Гамәлгә куючы файдаланылмый калган максатчан субсидияләр калдыкларын агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрү турында карар кабул итмәгән очракта, средстволар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

9. Файдаланылмый калган субсидияләр калдыкларын түләтү ТР Финанс министрлыгының 02.03.2016 ел, № 21-53-10 боерыгы нигезендә хәл ителә.